ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2025 елның «10» сентябреннән — № 187

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эш төркеме төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эш төркеме (алга таба текст буенча - эш төркеме) төзергә

2. Расларга:

эш төркеменең составын (1 нче кушымта);

эш төркеме турында нигеэләмәне (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «10» сентябреннән
187 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча
Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эш төркеме составы

Эш төркеме рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Еронтьев Александр Леонидович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча); |

Эш төркеме рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Гурьева Наталья Николаевна | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Кашаева Ольга Ивановна | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексլы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районындагы өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Бочарова Анастасия Алексеевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| Бутина Анна Ивановна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге башлыгы |
| Лизунова Зәлина Наил кызы | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен Яңа Чишмә интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Мартышова Светлана Вячеславовна | - | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Пузикова Нина Ивановна | | Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды бүлегенең Яңа Чишмә районында клиентлар хезмәте башлыгы (бүлек хокукларында) (килешү буенча) |
| Роменская Наталья Александровна | - | «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «10» сентябреннән
187 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эш төркеме турында нигезләмә

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эш төркеме (алга таба - эш төркеме) «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту, өлкән буын гражданнарының тормыш активлыгын күтәрү, аларның гомер озынлыгын һәм актив озын гомер чорын арттыруга ярдәм итү өчен төзелә.

2. Эш төркеме үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый актлары белән җитәкчелек итә.

3. Эш төркеменең төп функцияләре түбәндәгеләр:

өлкән буын гражданнарының актив озак яшәвен озайту, аларның шәхси потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

өлкән буын гражданнарның сәламәтлеген саклау, медицина ярдәмен үстерү, шул исәптән «гериатрия» профиле буенча;

сәламәт тормышны озайтучы һәм сыйфатлы тәрбияләүне тәэмин итүче өлкән буын гражданнары өчен социаль хезмәт күрсәтүләрне үстерү;

өлкән буын гражданнарының финанс тәэмин ителешен күтәрү, аларны эш белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

өлкән буын гражданнарының сыйфатлы һәм имин тормышы өчен инфраструктураны үстерү.

4. Эш төркеме турында нигезләмә һәм эш төркеменең персональ составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Эш төркеме составына эш төркеме рәисе, эш төркеме рәисенең урынбасары, эш төркеме секретаре һәм эш төркеме әгъзалары керә.

Эш төркеме рәисе - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча).

5. Эш төркеме рәисе эшче төркем эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, эш төркеме әгъзаларына йөкләмәләр бирә, эш төркеме утырышын уздыру датасын, урынын һәм вакытын билгели, эш төркеме тарафыннан башкарыла торган функцияләр кысаларында башка мәсьәләләрне хәл итә.

6. Эш төркеме секретаре эш төркеме карарларының, эш төркеме рәисе йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тора, эш төркеменең утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә, эш төркеме рәисенең башка йөкләмәләрен үти.

7. Эш төркеме утырышлары кирәк булган саен утырыш рәвешендә уздырыла.

Эш төркем еутырышын эш төркеме рәисе яисә аның кушуы буенча эш төркеме рәисе урынбасары алып бара.

Эш төркеме карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул эш төркеме утырышында рәислек итүче һәм эш төркеме секретаре тарафыннан имзалана.

Кирәк булганда эш төркеме утырышына иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре, башка затлар чакырылырга мөмкин.